КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 декабрь

г.Казань

№ 1352

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек башкару турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 28 июнь, 507 нче карары белән расланган Индустриль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек башкару турында килешү төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Индустриль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек башкару турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 28 июнь, 507 нче карары белән расланган Индустриль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек башкару турында килешү төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«вәкаләтле оешма - «Татарстан Республикасы кластерлы үсеш һәм проект идарәсе үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы, үз эшчәнлеген әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максат нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан заявкаларны җыюны һәм карауны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кластерлы үсеше һәм проект идарәсе үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2022 ел, 20 апрель, 374 нче карары нигезендә гамәлгә ашыра;»;

3.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча Килешү төзү турында гариза, вәкаләтле орган (индивидуаль эшкуар өчен) билгеләгән форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык белән;»;

5.5 пунктның икенче абзацында «мөрәҗәгать итүче» сүзләреннән соң «өч ел рәттән» сүзләрен өстәргә;

әлеге  Тәртипкә 2 нче кушымта таблицасыннан соң беренче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин